ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КЗЫЛТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАРЫ

2024 ел, 23 сентябрь № 128

Кзылтау авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Кзылтау авыл җирлеге Советы карар итте:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Кзылтау авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 14 ноябрендәге 84 нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4)Әлеге пунктның 4.2 пунктчасында билгеләнгән очраклардан тыш, Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына

Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына

2015 елда – 1,2 процент, 2016 елда – 1,5 процент, 2017 елда – 1,8 процент, 2018 елда һәм аннан соңгы елларда – 2 процент;”;

2)2 пунктның 4.1 пунктчасында «2 процент» сүзләрен «2,5 процент»сүзләренә алмаштырырга;

3) 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле 4.2 пунктча өстәргә:

«4.2)2027 елның 31 декабренә кадәр Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы тарафыннан Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган административ-эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларына) һәм алардагы бүлмәләргә карата 1,2 процент;»;

4) 2.1 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

5) 2.2 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Салым ташламасы Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Кзылтау авыл җирлеге территориясендә билгеләнгән тәртиптә яшәү урыны буенча теркәлгән салым түләүчеләргә салым түләүче милкендәге һәм эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган салым салу объектына карата салым түләргә тиешле салым суммасы күләмендә бирелә.».

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының «Кзылтау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставында билгеләнгән тәртип нигезендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Апас муниципаль районы
Кзылтау авыл җирлеге башлыгы М.Г. Нуриев